*Слайд№1(исеме)*

**«Татарстан Республикасындадәүләтмиллисәясәтентормышкаашыру»**

**Хәерле көн хәрмәтле Марат Готыф улы, халык депутатлары, утырышта катнашучылар!**

Милләтара һәм динарамөнәсәбәтләрне һәм татулыкны ныгыту, Татарстандаяшәүче халыкларның телләрен саклау, мәдәниятларынүстерү, чит илдәнкилүчеләрнеҗәмгыятебездә уңышлы социаль һәм мәдәни яктан адаптацияләү, гомумроссия гражданлык һәм республикаүзаңын ныгыту – Татарстан республикасының дәүләт милли сәясәтенең төп бурычлары булып тора.

*Слайд №2 (программалар)*

Дәүләт мәдәни сәясәтен тормышка ашыруның төп механизмы -дәүләт программалары: "Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру”, “Татар халкының милли үзенчәлеген саклау", " Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү", “Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү". Алар нигезендә республикада**дүрт йөз илледән(450) артык** мәдәни, мәгариф чаралары, фәнниэзләнүләр, иҗади һәм иҗтимагый проектларгамәлгә ашырылды.

Мәдәният министрлыгы Татарстанда яшәүче халыкларның этно-мәдәни үсеше белән бәйле чараларны министрлыклар, дәүләт оешамалары, фәнни һәм иҗтимагый оешмалар, иҗади берлекләр белән тыгыз хезмәттәшлектә башкара.

*Слайд № 3 (милли сәясәт)*

**"Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру"** программасының узган елда үтәлеше – 100 %, аның нигезендә 74 чара гамәлгә ашырылды. Шул исәптән махсус финансланган чаралар – 43,

министрлыкларның төп эшчәнлеге кысаларында -31 чара каралган иде.(*2020 елда 82 чара каралган иде, пандемия сәбәпле 82 чара арасыннан 40 чараның гамәлгә ашырылуы туктатылды*)

Былтыр дәүләт программасын финанслау өчен **58**млн-нан артык сум бүлеп бирелгән: 48 млн-нан артыгы республика хисабына, 10 млн артыгы – федераль үзәктән кергән акча.

***Слайд №4 ( финанслау)***

Слайдларда сез узган елда финансларның кулланышын күрә аласыз.

***Слайд №5 (индикаторлар)***Программада билгелгеләнгән индикаторлар шулай ук тулысы белән үтәлгән.

***Слайд №6 (милли узенчәлек)***

Былтыр"**Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»**дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларындаҗитмеш тугыз (79) чара планлаштырды, шуларныңҗитмеш сигезе гамәлгә ашырылды (*Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре форумыкичектерелде*).

*Шул исәптән махсус финансланган чаралар -63, максатлы финанслауны таләп итмәгән 15 чара каралган. (2020-нче елда планда - 57 чара, шуларның 48 гамәлгә ашырылды).*

***Слайд №7 (финанслау)***

Узган елда әлеге дәүләт программасына йөз җиде миллионнан артык акча бүлеп бирелде. Алар тулысы белән үзләштерелгән.

***Слайд №8 (индикаторлар)***

**Слайдларда - финансларның һәм индикаторларның үзләштерелүе күрсәтелгән.**

***Слайд №9 ( туган телләр елы)***

Үткән елда **Татарстан Республикасында туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы**кысаларында республикада яшәүче халыкларның рухиятен, гореф-гадәтләрен саклау һәм популярлаштыру максатыннан **12 меңнән** артык чара үткәрелде.Алар арасында - традицион үткәрелә торган чаралар һәм яңа проектлар.

Чаралар республика планы белән бер рәттән, ведомство, районнар планнары нигезендә гамәләгә ашырылды. Унбер мең биш йөзгә якын чара - муниципалитетлар тарафыннан уздырылды, шуларның 5 меңгә якын чарасы –мәдәният өлкәсендә, якынча 3 мең сигез йөзе – мәгарифтә, иҗтимагый-сәяси чаралар– мең йөз алтмыштан артыгы.

Туган телләр һәм милли бердәмлек елы - республиканың мәдәни һәм иҗтимагый тормышының бер идеологик нигезе булып торды һәм алга таба аның үсешенә яңа юл ачты.

Максатларыбызны үтәүдә Бөтендөнья татар конгрессы, Халыклар дуслыгы ассамблеясы, Халыклар дуслыгы йорты һәм милли мәдәни автономияләр төп роль уйнады. Алар белән бер рәттән фәннәр академиясе, җәмәгать палатасы, мәдәни, мәгариф, дини, иҗтимагый оешмалар, иҗади берлекләр, киң җәмәгатчелек катнашты.

Этномәдәни проектлар узыдруда, кызыклы формалар табуда иң активлары - Актаныш, Кукмара, Апас, Түбә Кама, Әлмәт, Арча, Алабуга, Чирмешән районнары, Яр Чаллы һәм Казан шәһәрләре.

***Слайд №10 (мәңгеләштерү)***

Мәдәни вакыйгаларыбыз күренекле шәхесләрнең юбилейлары белән үрелеп бардылар: Сәиф Сараиның 800 еллыгы, Тукайның 135 еллыгы, Һади Такташның 120-еллыгы, Җәлилнең 115 еллыгы, Нәҗиб Жиһановның 110 еллыгы, Рөстәмнең Яхинның 100 еллыгы, Әнвәр Бакировның 100 еллыгы,Николай Фешинның 140-еллыгы һәм башкалар.

Шуңа өстәп: Казан паркында Кәрим Тинчуринның бюсты, Екатеринбургта Муса Җәлилнең, КФУ бакчасында Сергей Аксаковның бюстлары куелды. Истәлек такталары Кави Нажми һәм аның хатыны,

әдәби тәрҗемәче Сарвар Әдһәмовага, бөек җырчыбыз Вафира Гыйззәтуллинага, фронтовик-язучы Геннадий Паушкинга, композитор Сара Садыйковага, халык шагыйре Фәнис Яруллинга куелды.

*Слайд №11 (материаль булмаган мәдәни мирас)*

**Дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның** зур бер юнәлешен **материаль булмаган мәдәни мирас** үрнәкләрен өйрәнү, барлау, саклап калу һәм үстерү эше алып тора. 1 апрельдә, гамәлдәге законнар кысаларында, "**Татарстан Республикасының матди булмаган мәдәни мирасының электрон реестры"** мәгълүмат системасы эшли башлады, анда һәр муниципалитетның "эш кабинеты" булдырылды. Һәр берәмлек фото, видео, аудио материаллары белән бирелә. Былтыр уздырылган мониторинг нәтиҗәсендә теркәлгән объектларның гомум саны - 180.

*Слайд №12 ( халык бәйрәмнәре)*

**Татарстан Республикасындагы халык бәйрәмнәре һәм фестивальләре-** Россиянең күпмилләтле культурасының уникаль күренеше буларак күз аллана. Былтыр "Каравон" фольклор фестивале, "Уяв" чуваш бәйрәме, "Учук" Кама арты чувашлары бәйрәме, удмуртларның "Гырон Быдтон", мордва халкының "Балтай", славян “Иван Купала ", марыйларның"Семык ", керәшен татарларының"Питрау” онлайн һәм оффлайн форматта да узды.

Онлайнда - бәйрәмнәрнең тарихы һәм традицияләре күрсәтелде, остаханәләр үткәрелде.

*Слайд №13 ( халык бәйрәмнәре – мониторинг)*

**Соңгы елларда үткәрелгән халык бәйрәмнәре буенча әзерләнгән мониторинг нәтиҗәләре белән экранда таныша аласыз.**

*Слайд №14 (Сабантуй)*

**Т**өп милли бәйрәмебез - Сабантуй, тарихи-мәдәни мирасны саклап калуда һәм популярлаштыруда аеруча рольне үти.

Былтыр 386 Сабантуй үткәрү планлаштырылган иде, шул исәптән 294е – Россиянең 56 төбәкләрендә, 92 е – якын һәм ерак чит илләрдә. **Россия төбәкләрендә 102 Сабантуй узды**. 192 Сабантуй коронавирус таралу сәбәпле уздырылмады.

**Чит илләрдә 18 Сабантуй узды**. Үзбәкстан, Таҗикстан, Кыргызстан, Белоруссия, Румыния, Америкага, Бельгиягә иҗат коллективлары җибәрелде.

18-19 июнь көннәрендә Нижневартовскта **XXI федераль Сабантуй** узды. Концертны онлайн-форматта 25 меңнән артык кеше карады.

26-27 июньдә Кемерово шәһәрендә «Кузбасска 300 ел»халыкара шахтерлар Сабантуе узды, анда 5 меңңнән артык кеше катнашты.

2 июльдә Мөслим авылында Татарстан  сәнгать осталары концерты узды, ә 3 июльдә XI Бөтенроссия авыл Сабантуе узды.

Барлыгы 120 Сабантуйда бөтен республикадан 1 500дән артык артист һәм халык сәнгате һөнәрчелеге осталары катнашты.

***Слайд №15 ( семинар)***

Татарстан инде 15 елдан артык ел саен Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче режиссерларга, «Сабантуй» бәйрәмен оештыручыларга **бәйрәмебез уздыру нигезләрен укыта**. БыелРоссиянең 27 төбәгеннән 50 кеше һәм чит ил вәкиле катнашты

*26-29 апрельдәМәдәният министрлыгы Бөтендөнья татар конгрессы һәм “Мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм гореф-гадәтләрне саклау ресурс үзәге» белән берлектә Россия төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче режиссерлар һәм оештыручылар өчен семинар-практикум уздырды. Укулар  ике форматта да узды. Семинарның онлайн-форматында Россиянең 27 төбәгеннән 50 кеше һәм чит ил вәкиле катнашты. Чаралар ике дәүләт телдә үтте.*

***Слайд №16 ( яңа проектлар)***

2021 ел яңа иҗади проектларга бай ел булды. Шулар арасында:

**- Туку буенча халыкара симпозиум** -министрлык һәмГалимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының уртак проекты (27.06.2022-03.07.2022).

*Танылган Кырым татар остасы Мамут Чурлу тарафыннан семинар үткәрелде. Сәнгать мәктәпләренең 15 укытучысы, Актаныш, Бөгелмә,Буа, Яр Чаллы, Кукмара, Казан музей хезмәткәрләре табигый буяулар белән буяу күнекмәләрен алдылар һәм кул туку һөнәрен өйрәнделәр. 20–21 декабрьдә, "Күпмилләтле туку сәнгате" симпозиумы татар сәнгате өйрүнүгә нигез салучы Фоат Вәлеевның 100 еллыгына багышланган. Кырымдагы семинарда катнашучыларның соңгы әсәрләре тәкъдим ителде. Конференциядә5 чит ил галиме һәм осталары катнашты (якынча 500 кеше).*

***Слайд №17 ( яңа проектлар)***

**23 - 27 июльдә Казанда "Тормыш стиле -мәдәни код" халык сәнгате һәм һөнәрчелек этно-мода фестивале** уздырлды.

Камал театры мәйданында һөнәрчеләрнең күргәзмәсе һәм дизайнерларының ярминкәсе узды. 50 чатырда кулдан эшләнгән милли мода әйберләре һәм 150 дән артык осталар эшләре тәкъдим ителде. Чарада 15 мең кеше катнашты.

*Фестивалдә**"Ел остасы - 2021"** конкурсы җиңүчеләре бүләкләнде. Халык сәнгатенең 22 остасына призлар һәм дипломнар тапшырылды. Кагыйдә буларак, бүгенге көндә һөнәрчеләр кечкенә торак пунктларда яшиләр һәм үсеш өчен мөмкинленләре күп түгел. Ләкин шул ук вакытта алар кәрзин туку, чигү осталыгы, күн, таш, балчык һ.б. турында белем йөртүчеләр. Бүгенге көндә ул заманча маркетплейс мәйданнары киңлекләрендә эшли ала. Мәсәлән, www.kasanexpress.ru, сайтында Татарстан һөнәрчеләренең халык сәнгате товарларын сату өчен махсус юнәлеш булдырыла. Агымдагы елда, Wildberries, OZON электрон*

*платформалары дистәләгән халык сәнгате осталары тарафыннан үзләштерелгән.*

***Слайд №18 ( яңа проектлар)***

**20-21 декабрьдә "Татарханә"** тарихи-мәгариф проектының презентациясе булды. Чаралар сериясе **Татфолк YouTube каналында** туры эфирда күрсәтелде, мәсәлән милли ашлар остаханәләре. 2 көн дәвамында проектны Россиянең 55 төбәгеннән һәм чит илләрдән өч ярым мең кеше карады.

"*Татар табыны" бүлегендә "Килен токмачы", "Кияү пилмәне", "Каклаган каз" һ.б. һәм хәзерге татар яшьләренең стиле һ.б.*

***Слайд №19 ( яңа проектлар)***

Инде икенче елрәттән Республикада"**Уен Фест" традицион халык уеннары фестивале**уза, анда 2300 уен спектакле һәм остаханәсеуузды.Бу проект балаларгагореф-гадәтлеребезне таныту мөмкинлеген бирә, аларда тормышта кирәк булган заманчакүнекмәләрне дә үстерә. Фестивальдә барлык театрлар, мәдәният институты студентлары, мәдәният йортлары хезмәткәрләре канташты. Балалар белән бергә -130 мең кеше. Уен-фестны социаль челтәрләрдәмиллионга якын кеше күрде

***Слайд №20 ( яңа проектлар)***

Дәүләт Советының татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе ярдәме белән "Татаркино" белән берлектә беренче **Республика «Милли мультфест» фестивале** үткәрелде.

*(чарада: республиканың 39 районыннан 2000дән артык катнашучы, 389 гариза, 152 анимацион фильм, 164 кыска метражлы фильм, 73 компьютер уены).*

***Слайд №21 ( яңа проектлар)***

Декабрьдә, Камал театры сәхнәсендә**Ш.Закиров исемендәге "Идел-Йорт" театр төркемнәренең төбәк ара конкурсының**финалы үткәрелде. Ел дәвамында Татарстан дәүләт театрларында режиссерлар һәм "халык үзешчән төркеме" мактаулы исеме булган үзешчән театр актерлары өчен иҗади лабораторияләр уздырылды.Барлыгы фестивальдә 66 театр төркемеһәм Россия Федерациясенең 16 төбәктөркемекатнашты.

*Слайд №22 ( килешүләр)*

**Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә даими яшәүче ватандашлар белән элемтәләрне ныгыту, Татарстан белән мәдәни һәм фәнни хезмәттәшлек**не киңәйтү - өстенлекле юнәлешләренең берсе. Бу эшнең хокукый нигезе - хөкүмәт дәрәҗәсендә килешүләр төзү. Алар 79 төбәк һәм 22 чит ил белән төзелде, шуңа өстәп 37 ведомствоара килешүләргә кул куелды.

*Ел саен Татарстаннан рәссамнарны, иҗат вәкилләрен,белгечләрне Россия һәм чит илләргә мастер-класслар башкару өчен, шулай ук төрле конкурслар һәм фестивальләрҗюри әгъзалары буларак җибәрә. 2021-нче елда, Татарстан Республикасы һәм илнең регионнарындагы дәүләт һәм муниципаль театр һәм күңел ачу учреждениеләренең гастрольләре һәм сәяхәтләре саны 777, Мәскәү, Санкт-Петербург, Тула, Сочи; Ханти-Манси Автоном Округ, Удмурт Республикасы, Башкортостан Республикасы, Мордовия Республикасы, Чуаш Республикасы, Пермь Территориясе, Дагыстан Республикасы һ.б.*

*Слайд №23 (Нәүрүз)*

7 -11 июндә **төрки халыкларның "Нәүрүз" унбишенче Халыкара театр фестивале уздырылды**. Казаныбызда Казакъстан, Әзербайҗан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Кыргызстан һәм Россия төбәкләреннән театр төркемнәре җыелды. Фестивальдә меңнән артык кеше катнашты.

*Слайд №24 (Күргәзмә)*

Күргәзмәләр - милли-мәдәни тормышының мөһим компоненты. Июльдә "Манеж" күргәзмә залында Әзербайҗан халыкара музейлар советы рәисе, милли келәм музее директоры Ширин Меликов **"Келәм сәнгате - мәгънәләр эволюциясе" күргәзмәсен**ачып җибәрде, күргәзмә киң катлам белгечләрне үзенә җыйды.

*Слайд №25 ( конкурс Г. Тукай)*

Татарстан Республикасының Театр хезмәткәрләре берлеге, татар федераль милли мәдәни автономиясе белән берлектә, ел саен**Тукай исемендәге халыкара укучылар конкурсын үткәрә**. Бәйгедә Татарстан катнашучыларыннан кала, Россиянең башка төбәкләреннән мәктәп укучылары да катнаша. Быел 14 төбәк катнашты

*Башкортостан, Бурятия, Мордовия, Мари Эл, Удмуртия, Чувашия, Краснодар, Красноярск һәм Пермь өлкәләре, Волгоград, Түбән Новгород. Ульяновск, Пенза һәм Свердловск өлкәләре*.

*Слайд №26 (кино)*

**Татар телен өйрәнү һәм куллану өчен милли кино зур роль уйный**. Татар фильмнары платформасы безнең республика режиссерларының иң яхшы кинолары белән таныштыра. Аларны Татаркино YouTube каналында күреп була.

**Татарстан киносы көннәре** - Татарстанда төшерелгән фильмнар белән танышу өчен тагын бер мөмкинлек. Былтыр алар 2 илдә һәм 8 төбәктә узды.

*2021-нче елда Үзбәкстанда (Ташкент), Әзербайҗанда (Баку), Әстерхан һәм Түбән Новгород өлкәләрендә, Мәскәү, Омск, Оренбург, Самара, Уфа, Тольятти, Ханти-Манси автономияле округыкинотеатрларында үткәрелде.2021-нче елда республикада әрмән, славян, һинд, япон, литва,якут,поляк, башкорт, итальян киносы көннәре һ.б. уңышлы уздырылды.*

***Слайд №27 (кино фестивале)***

Горурлыгыбыз - **Казан мөселман киносы фестивале**шулай ук төрле диннәр һәм милләтләр өчен диалог мәйданчыгы булып тора. Былтыр конкурс программасына 50 фильм кертелде, шул исәптән ундүрте - Татарстан режиссерларының кинолары

Илдар Ягафаровның "Исәнмесез" фильмы, Галимҗан Ибрагимовның "Алмачуар" әсәренә нигезләнеп Алия Захарова иҗат иткән"Тарлан" киносы, Мөхәммәт Мәһдиевның "Без 41 ел балалары" әсәре нигезендә төшерелгән фильмнары экраннарга чыкты.

*Әлеге кино“Татар халкының милли үзенчәлеген саклау" программасы кысаларында финансланды. Фильмның бер өлеше Арча районы Гөберчәк авылында Мөхәммәт Мәһдиевның туган ягында төшерелде.*

***Слайд №28 (грантлар системасы)***

**Республикада милли проектлар үстерүгә юнәлдерелгән грантлар системасы** эшләү – ул яңа гына туган проектларга зур этәргеч, беренче мөһим ярдәм чыганагы. Дәүләт программалары белән бер рәттән, хөкүмәтебез билгеләгән әлеге грантлар, конкурслар да аеруча кирәкле ярдәм вазыйфасын үти. Мәсәлән, былтыр гына:

-**шәһәр татарһәм рус мәдәни-ял мохитен булдыру өчен грантлар** өчен конкурста400 мең сумлык 5 проект җиңде (*32 гариза)*

-Татарстан хөкүмәтеннән **этно-мәдәни проектларны тормышка ашыручы Россия регионнарындагы иҗтимагый оешмаларга** барлыгы 10 млн сумга 30 проектка акча бирелде (*54 гариза*);

- Татарстан хөкүмәтеннән**Халык сәнгате һәм һөнәрчелек өлкәсендә кече һәм урта бизнеска булышу өчен конкурстта** барлыгы 5 млн сумга 12 проект җиңеп чыкты (*37 гариза*).

Былтыр Татарстан хөкүмәтеннән туган **телләр саклауга юнәлтелгән проектларны тормышка**ашыру максатыннан муниципаль мәдәният

оешмалары өчен конкурс уздырылды. 100 проектка гомуми күләмдә 50 млн сумгаярдәм күрсәтелде. *(196 гариза кабул ителде).*

Шул конкурс кысаларындакүп кенә кызыклы яшьләр проектлары булдырылды: Болгар китапханәсендә һәм Яр Чаллы татар драма театрында татар каллиграфиясе күргәзмәсе, Аксубайда һәм Чаллыда “Кыскасы” яшьләр әдәби лабораториясе һәм остаханәләре, Әлмәттә һәм Казанда балалар милли музыкаль лабораториясе, Буада Шаяннар һәм тапкырлар клубының зональ уеннары, Шәриф Камал исемендәге премия һәм әдәби тәрҗемәчеләр семинарлары, болгар археологик шәһәрлекләре буенча “Болгар маршруты” һәм Казан арты авыллары буйлап он-лайн аудиогид, “XX гасырның 100 татар җыры” ресурсы. Бу һәм башка яңа яшьләр проектлары дәвамлы булачак һәм үсәчәк дип өметләнәбез.

**Татарстан хөкүмәтенә, Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевичка, Марат Готыфович - сезгә аеруча рәхмәтебезне белдерәбез. Киләсе елларда да әлеге проектларга ярдәм күрсәтү эше дәвам итәр дигән өметтә калабыз.**

***Слайд №29 (НКО, иҗади берлекләр)***

Татарстанда эшләп килүче иҗтимагыйоешмалар, иҗади берлекләр милли сәясәттә һәм мәдәни тормышта аеруча зур роль уйный. Ныклы хезмәттәшлек 60 артык иҗтимагый оешма белән бара.Республиканың 8 иҗат берлегебалалар һәм яшьләр катнашында районнарыбыздайөзгә якынчара үткәрделәр.

Мисал буларак, Татарстан Республикасы язучылар берлеге катнашында, беренче тапкыр **Роберт Миннуллин исемендәге балалар һәм яшьләр өчен** иң яхшы әдәби әсәр конкурсы үткәрелде. Барлыгы 74 катнашучы, шуларның 30% тан артыгы - яшьләр.

Тагын бер күркәм мисал. Рәшит ВаһаповФонды традицион **Ваһапов исемендәге халыкара татар җыр фестивале**ннән тыш, икенче тапкыр**Яна Татар җыры бәйгесе**н тормышка ашырды. Бу чараларда 30

меңнән артык тамашачы катнашты.Декабрьдә беренче тапкыр «Шәрык базары» Беренче Халыкара төрки халыклар эстрада фестивале узды. Аны да олы юлга чыгуын теләп калабыз.

***Слайд №30 ( яшьләр проектлары)***

Яшьләрнең иҗади проектлары - министрлыкның мөһим бурычларының берсе. Татар яшьләре форумы белән берлектә "Печән базары", “Җәдид фест”, "TAT CULT FEST" фестивальләре, "Мин Татарча сөйләшәм!" , акцияләре  уздырыла. Аларның даими аудиториясе40 меңкешегә җитә. Өченче тапкыр үткәрелгән TAT CULT FEST" татар альтернатив музыкасы, милли әдәбият, медиа сәнгате, дизайн һәм сынлы сәнгать җанатарларын җыйды. Казан Кремленда үткәрелгән әлеге чарага якынча 30 мең кеше килде.

***Слайд №31 (2022 ел, милли электрон китапханәсе)***

Бүгенге көндә цифрлаштыру дөньяның аерылгысыз өлеше, ул милли мәдәниятне, тарихны, телне, гореф-гадәтләрне өйрәнергә, кулланырга этәргеч бирә, дөньяның төрле почмакларына таратырга яңа мөмкинлекләр ача. Татарстанның милли электрон китапханәсендә 90 меңнән артык китап йөкләнелгән https://kitap.tatar.ru.

Милли Китапханә уникаль документларны цифрлаштыру эшен дәвам итте, шул исәптән –милли тарихыбызга кагылышлы уникаль басмалар. Проект башланганнан бирле барлыгы 30 мең якын документ берәмлеге цифрланган.

*"Хезмәтләрне цифрлаштыру һәм мәдәният өлкәсендә мәгълүмат киңлеген формалаштыру" региональ проекты кысаларында, "Санлы Мәдәният" федераль проектының ("Мәдәният" милли проекты), китап һәйкәлләре билгеләре булган 250 документ цифрланган. Һәм милли электрон китапханә  порталына урнаштырылды.*

Гомумән алганда, бу коллекциядә бүгенге 750 документ бар. Китапханә фондларын цифрлаштыру эше 2022 елда да дәвам итәчәк.

***Слайд №32 (“Татарстан аһәңнәре”)***

"ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан Мәдәният министрлыгы Татарстан Республикасы композиторлар берлеге белән берлектә,**“Татарстан аһәңнәре” музыкаль-мәгълүмати порталы**н булдырды, аның максаты-милли классиканы Татарстаннан ерак төбәкләргә якынайту.

***Слайд №33 (Шәрык клубы)***

Узган елда К**амал театрының " Шәрыкъ клубы"** исемле татар театры тарихының интерактив мультимедиа комплексы ачылды.

*Комплекста “Вакыт елгасы” (театрның видео елъязмасы булган экран стенасы), “AR-буклет” өстәлгән чынбарлык, “Арткы сәхнә” (виртуаль грим бүлмәсе, киенү бүлмәсе, театр буенча виртуаль экскурсия), “Фантом театры” (спектакльләрнең фрагментларын, шәхси катнашу иллюзиясен тудырган монтаж), “Театр. Тарих. Шәхес ”(милли театр сәнгатен формалаштыруда мөһим роль уйнаган күренекле шәхесләр һәм тарихи вакыйгалар турында интерактив проекция китабы), “ Пазл ” интерактив-табышмак һ.б. кебек зоналардан тора.*

***Слайд №34 (виртуаль концерт заллары)***

Мәдәниятыбызны танытуның тагын бер мөмкинлеге - виртуаль концерт заллары.Гомумән алганда, ачылганнан бирле әлеге залларда 200 дән артык чара үткәрелде. Былтыр алар Әлмәттә һәм Яр Чаллыда ачылды, элегрәк 5 районда булдырылды.

*Арча, Баулы, Спасс, Алабуга, Мамадыш районнары мәдәният учреждениеләре нигезендә ачылды, 2021 елда – Әлмәт һәм Яр Чаллыда, 2022 елда әлеге залларны - Түбән Кама, Менделеев районнары мәдәният учреждениеләре нигезендә тагын 3 виртуаль зал булдыру күздә тотыла.*

*Слайд №35 (мультимедиагид)*

**Мультимедиагид** кулланмасы - "Мәдәният" илкүләм проекты кысаларында тормышка ашырыла торган тагын бер проект. Бүгенге көнгә ARTEFACT платформасында Татарстанның 4 музее тәкъдим ителә: Милли музей, Ислам мәдәнияте музее, Казан Кремле һәм Татарстан сынлы сәнгать музейлары. Шуңа өстәп 3 виртуаль музейэшли.

Татарстанныңбарлыкмәдәниятоешмаларының чаралларыИнтернетта актив тәкъдимителә. Концертларһәмспектакльләр, күргәзмәләр һәм экскурсияләр, иҗади очрашулар һәм остаханәләр, лекцияләр һәм флеш-моблар, шулай ук онлайн чараларның башка кызыклы формалары цифралы форматта тәкъдим ителә.

*Слайд №36 (перспективалар,2022 ел)*

Татарстанда агымдагы ел мөһим чараларга бай:Россиядә халык сәнгате һәм матди булмаган мәдәни мирас елы; ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче утырышы. Бу дөнья мәдәни тормышында Татарстанның ролен тану гына түгел, ә тарихи мирасны саклау һәм уникаль һәйкәлләрне торгызу өчен республикада алып барылган зур күләмле эзлекле эш нәтиҗәсе.

Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы. Бу олы юбилеебыз – Татарстанда милләт ара, дин ара татулыгының, ныклы терәге, милли мәдәниятыбзны үсеш нигезе булыр дип ышанабыз.

**Слайд №37**Игътибарыгыз өчен рәхмәт!